| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.12.2020 г.Казань № 876

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 27 гыйнварендә 7525 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының $11^1$ кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 №484, 16.08.2019 № 624, 14.11.2019 № 1023, 18.06.2020 № 436, 27.07.2020 № 536, 24.09.2020 № 669 боерыклары нигезендә

кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының $11^1$ кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11[1]кушымта (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.12.2020 №876 боерыгы редакциясендә)

Гражданинны өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндез килеп тору төркемнәрендә өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбия кылу системасын оештыру буенча 2020-2022 елларда сынау проектында катнаша торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле, яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар * | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча хосусый программа** | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны хосусый тернәкләндерү яисә абилитацияләү программасында күрсәтелгән |
| 3. | Өлкән кешенең хәтер (деменция, картларча астения) яки когнитив житешсезлекләр булуын раслый торган белешмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яки яшенә бәйле рәвештә төп яшәеш ихтыяҗларын тәэмин итүдә өлешчә мөмкинлеген югалтуы турында белешмә *** | | |

* - билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез дип танылган затка хезмәт күрсәтүгә керешкәндә, мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан гариза тапшырылган очракта бирелә;

** - инвалидларның федераль реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта инвалидларга бирелә;

*** - өлкән яшьтәге гражданнарга бирелә.